Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге составына керүче Яна Аксубай авылында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2019 елның 27 ноябре № 8

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Яңа Аксубай авыл җирлегенең Яңа Аксубай торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2020 елда Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге Кече Аксубай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, гражданнар өчен 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

-Яңа Аксубай торак пункты чикләрендә юл полотносы урнаштыру;

- Яңа Аксубай авылы эчендәге юлларны кышкы чорда карап тоту.

2) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктыртуны да кертеп);

- Яңа Аксубай торак пункты чикләрендә урамнарны яктыртуны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу.

3. Әлеге карарны Яңа Аксубай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында http://aksubaevo.tatar.ru урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Аксубай
авыл җирлеге башлыгы М. М. Сөләйманкин